КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 17 июль г.Казань № 594

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 ноябрь, 1036 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 52 нче; 2013 ел, 29 июнь, 458 нче; 2014 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы; 2014 ел, 15 февраль, 91 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 июль, 553 нче; 2014 ел, 2 август, 565 нче; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 22 октябрь, 775 нче; 2015 ел, 2 апрель, 209 нчы; 2015 ел, 22 июль, 536 нчы; 2015 ел, 3 ноябрь, 833 нче; 2016 ел, 26 май, 356 нчы; 2016 ел, 30 июнь, 449 нчы; 2017 ел, 16 март, 144 нче; 2017 ел, 20 июнь, 400 нче; 2017 ел, 5 сентябрь, 636 нчы; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2018 ел, 14 июнь, 482 нче; 2018 ел, 15 июнь, 486 нчы; 2018 ел, 16 ноябрь, 998 нче карарлары белән

кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 нче пункт таблицасыннан соң абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балалар һәм үсмерләр өчен социаль приютларның, акылга зәгыйфьләр өчен балалар интернат йортларының педагог хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр өчен база (вазыйфаи) окладына тармак өстенлеге коэффициенты кулланыла.

Тармак өстенлеге коэффициенты күләме түбәндәгеләрне тәшкил итә:

педагог хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган беренче – өченче квалификация дәрәҗәләрендәге хезмәткәрләр өчен – 1,4;

педагог хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган дүртенче квалификация дәрәҗәсендәге хезмәткәрләр өчен – 1,5.

Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм үсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләренең педагог хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр өчен база (вазыйфаи) окладына тармак өстенлеге коэффициенты кулланыла.

Тармак өстенлеге коэффициенты күләме түбәндәгеләрне тәшкил итә:

педагог хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган беренче – өченче квалификация дәрәҗәләрендәге хезмәткәрләр өчен – 1,34;

педагог хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган дүртенче квалификация дәрәҗәсендәге хезмәткәрләр өчен – 1,44.

Әлеге коэффициентларны база окладына карата куллану яңа база окладын барлыкка китерә һәм компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне исәпләгәндә исәпкә алына.».

2. Бу карарның гамәле 2019 елның 1 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин